**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**23 март 2021 ел** **№ 50**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Муниципаль милектә булган җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибе турында» 2017 елның 23 мартындагы 84 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.7 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 елның 9 февралендәге 74 номерлы карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат муниципаль районы Советының 2017 елның 23 мартындагы 84 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмен билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

тәртипнең 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Аренда түләве арендага җир кишәрлеге бирү аеннан соң килә торган айдан башлап исәпләнә, шул исәптән төзелеш чорына да, һәм арендатор тарафыннан ай саен кертелә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясындагы 2 пунктында каралган объектларны урнаштыру өчен, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару өчен бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве федераль башкарма хакимият органнары тарафыннан расланган аренда түләве ставкалары белән исәпләнелә.».

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы Советының сәнәгать, транспорт, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе А.С. Әхмәтшин